СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 2 » февраль 2021 ел** **№ 43**

**Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу Тәртибе турында**

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясындагы 1 һәм 2 өлеше, "Урта һөнәри һәм югары белем бирү программалары буенча максатчан укыту турында" Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, җирле үзидарә органнарын, муниципаль учреждениеләрне, Арча муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен, "Арча үзәк район хастаханәсе" ДАССУ һәм районның авыл хуҗалыгы тармагын югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, эш бирүчеләргә Арча муниципаль районы социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча урта һөнәри яки югары белемле белгечләр әзерләүне оештыруда ярдәм итү, шулай ук Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында, район хастаханәсендә һәм район агросәнәгать комплексы оешмаларында белгечләрне эштә калдыру өчен шартлар тудыру максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу Тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу комиссиясен төзергә һәм аның составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу комиссиясе турында Нигезләмәне 3 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ
ИНН 1609009523

1 нче кушымта
Арча район Советының
02.02. 2021 ел, № 13
карары белән расланган

**Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип бакалавриат, специалитет программалары буенча урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында (алга таба - мәгариф оешмасы) максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу шартларын билгели.

2. Белем бирү оешмасында максатчан уку өчен юллама алу хокукына Арча муниципаль районының җирле үзидарә органы белән максатчан уку турында шартнамә төзү нияте булган төп гомуми яисә урта гомуми белем алучы гражданнар ия.

3. Шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләрнең, «Арча үзәк район хастаханәсе» ДАССУ һәм районның авыл хуҗалыгы тармагының урта һөнәри яисә югары белемле белгечләргә булган перспективалы ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен гамәлгә ашырыла һәм белем бирү оешмасы билгеләгән һәр әзерлек (белгечлек) юнәлеше буенча максатчан кабул итү квотасы кысаларында уздырыла.

4. Белем бирү оешмасында максатчан укуга дәгъва итүчеләрне сайлау түбәндәге этапларны үз эченә ала:

шартнамә төзү өчен сайлап алуда катнашырга теләк белдерүчеләр, шулай ук конкурста катнашуга үз ризалыгын белдергән гражданнардан документлар кабул итү;

максатчан кабул итүдә катнашырга теләк белдергән гражданнар исемлеген формалаштыру өчен дәгъвачыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе эше;

дәгъвачылар тарафыннан ГДИ яки БДИ нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, дәүләт үрнәгендәге төп гомуми яисә урта гомуми белем турында документлар күчермәләрен бирү;

сайлап алуны уңышлы узган дәгъвачылар белән шартнамәгә кул кую;

максатчан кабул итү турында алдынгы югары уку йортлары белән шартнамәләр төзү.

5. Төп гомуми яисә урта гомуми белем алган урта һөнәри яисә югары белем алуга дәгъва кылучы затлар шартнамә төзүгә дәгъвачылар булалар.

6. Урта һөнәри яисә югары белем бирү программалары буенча белем бирү оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә сайлап алуда катнашу өчен дәгъвачы максатчан кабул итүдә катнашырга теләк белдергән гражданнар исемлеген төзү өчен дәгъвачыларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

максатчан укуга гариза;

паспорт күчермәсен (төп нөсхә белән);

дәгъвачыга гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан бирелгән характеристика -рекомендация;

белем бирү учреждениесе тарафыннан таныкланган 10 - 11 сыйныфларда агымдагы өлгереш белешмәләре (табеле);

белем бирү оешмасына керү өчен кирәк булган предметлар буенча сынау бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре;

шәхси казанышлар турында документлар (дипломнар, таныклыклар, белешмәләр, олимпиадаларда, конкурсларда җиңү (катнашу) турында грамоталар).

7. Документлар ел саен уку елының 1 мартыннан башлап кабул ителә.

8. Шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт: сайланган белгечлек буенча башлангыч бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре; укучының олимпиадаларда, конкурсларда ирешкән шәхси казанышлары;

9. Шартнамә төзүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларны тулы күләмдә тапшырмау һәм (яисә) дөрес рәсмиләштерелмәгән документлар тапшыру;

документларда күрсәтелгән белешмәләрнең тулы булмавы;

документларда күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавы;

өлгереш нәтиҗәләре түбән булу.

2 нче кушымта
Арча район Советының
02.02. 2021 ел, №
43 карары белән
расланган

Югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу комиссиясе
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мөхәммәтова Алсу Фирдәвесовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фәйзрахманова Эльвира Минзаһитовна | - башкарма комитетның гомуми-оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Мөхәррәмов Рәсүл Ринатович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Гатиятов Ринат Мансурович | - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча): |
| Мөхәммәтшина Алинә Таһировна | Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча); |
| Мөхәммәдияров Рамил Данилович | - башкарма комитетның «Мәгариф идарәсе» МУ башлыгы (килешү буенча) |
| Сәгыйтова Ләйсән Гарәфетдиновна | - Арча район Советының юридик мәсьәләләр буенча бүлеге башлыгы |

3 нче кушымта

Арча район Советының
02.02. 2021 ел, №43
карары белән расланган

**Урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва итүчеләрне сайлап алу комиссиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу комиссиясе (алга таба - Комиссия, максатчан уку турында шартнамә) максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу максатыннан төзелә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан уку турында" 2020 елның 13 октябрендәге 1681 номерлы карары ("Урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча максатчан уку турында нигезләмә", "Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирү программалары буенча максатчан уку-укыту квотасын билгеләү кагыйдәләре" белән бергә) һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучылардан үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

Комиссия Комиссия рәисеннән, Комиссия рәисе урынбасарыннан, Комиссия секретареннән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә.

Комиссия составы Арча район Советы карары белән раслана.

5. Комиссия утырышын Комиссия рәисе, ул булмаганда - Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

6. Комиссия утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

7. Комиссия секретаре:

документларны теркәү журналында максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъвачыларның документларын терки;

Комиссия утырышына материаллар әзерләүне тәэмин итә;

Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын үткәрү урыны һәм вакыты турында Комиссия утырышы көненә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итә;

Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм аны Комиссия утырышыннан соң 5 эш көне эчендә рәсмиләштерә;

урта һөнәри яисә югары белем бирү программалары буенча белем бирү оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә сайлап алу узган

гражданга Комиссия утырышыннан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсен яисә беркетмәдән өземтә җибәрә;

урта һөнәри яисә югары белем бирү программалары буенча белем бирү оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә сайлап алынган граждannар исемлеген республика мәгариф оешмалары белән максатчан уку турында шартнамәләр төзү өчен Арча муниципаль районы башкарма комитетына тапшыра;

Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

8. Документлар тулы күләмдә тапшырылмаган һәм (яисә) дөрес рәсмиләштерелмәгән очракта, Комиссия алар кергән көннән алып 3 эш көне эчендә кандидатка җитешмәгән документлар һәм (яисә) дөрес рәсмиләштерелмәгән документлар турында хәбәр итә.

9. Комиссия ел саен 1 мартка кадәр җирле үзидарә органнарыннан, Арча муниципаль районы муниципаль учреждениеләреннән, “Арча үзәк район хастаханәсе” ДАССУ, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Арча муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсеннән белгечләргә ихтыяҗ турында мәгълүмат соратып ала.

10. 5 мартка кадәр Комиссия район халкына киләсе уку елына республика мәгариф оешмаларында максатчан уку турында шартнамәләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерә. Мәгълүмат Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

Комиссия дәгъвачыларга агымдагы елга өстенлекләр һәм максатчан урыннарга керүнең башка шартлары турында хәбәр итә, аларның берсе- укуны тәмамлаганнан соң әлеге белгечләр белән максатчан уку турында шартнамәдә күрсәтелгән оешма белән хезмәт контракты төзү.

11. Комиссия максатчан урыннарны дәгъвалаучылардан 20 мартка кадәр урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алуны уздыру тәртибенең 7 пунктында булган исемлек нигезендә документлар кабул итә, урта һөнәри яисә югары белем бирүче мәгариф оешмасында максатчан уку турында шартнамә төзүгә дәгъва кылучыларны сайлап алу комиссиясе утырышы 30 мартка кадәр уздырыла.

12. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, Комиссия карарлар кабул итәргә хокуклы санала. Комиссиядә катнашучыларның күпчелеге хуплый икән, карар кабул ителгән дип санала һәм Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Ачык тавыш бирү үткәрелә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, рәиснең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия мәгариф оешмаларында максатчан белем алу турында шартнамә төзү яисә аны төзүдән баш тарту турында карар кабул итә.

13. Комиссия әгъзалары тигез хокукларга ия һәм Комиссия утырышында шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен бәян итәргә һәм

Комиссия карары кабул ителгәндә аның фикерен исәпкә алу өчен аны Комиссиягә җибәрергә хокуклы.

14. Ел саен 30 мартка кадәр Максатчан юллама бирү турында Комиссия карары кабул ителгән затларның (аларның законлы вәкилләре) исемлекләре формалаштырыла, 01 апрельгә кадәр республика югары уку йортларына квоталы кабул итү кысаларында укырга керүгә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасының тармак министрлыгына җибәрелә.

15. Максатчан кабул итүгә комачаулый торган хәлләр килеп чыккан очракта (укуны тәмамламау, БДИ нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмау, авыру, белем алуга комачаулаучы башка хәлләр) укучы (аның законлы вәкилләре) бу турыда Комиссиягә кичекмәстән хәбәр итә.

Мондый вакансияләр барлыкка килгәндә, Комиссия киткән укучыларны конкурска документларны вакытында тапшырган башка дәгъвачылар белән алыштыру чараларын күрә.